Резеда Шәрипова

Ялкау балыкчы

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ш 95



Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Шәрипова Р.С.

Ш 95 Ялкау балыкчы: Шигырьләр / Резеда Шәрипова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 48 б.

ISBN 5-298-03968-5

Азнакай шәһәрендә яшәүче Резеда Шәрипова шигырьләре балаларны дөньяга, тирә-якка игътибарлы булырга, матурлыкка сокланып үсәргә өйрәтә.

ISBN 5-298-03968-5 © Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Шәрипова Р.С., 2006

Резеда Шәрипова

Ялкау балыкчы

Шигырьләр

Рәссам *Алсу Тимергалина*

Казан 2006
Татарстан китап нәшрияты

Яшенле яңгыр

Бер тамчы,
Ике тамчы...
Уйнады яшен-камчы!
Ялтыр-йолтыр,
Шарт та шорт,
Исте җилләре тузгып,
Ачуланды бик яман,
Әйтерсең ахырзаман!
Актылар гөрләвекләр,
Җыелды күлдәвекләр.
Дөбердәп котырынды,
Котырынды да — тынды.
Ялтырап кояш чыкты,
Күккә салават сызды.
Кара инде, гел юктан
Шул яшеннән курыктым!

Батыр малай

Мин шундый матур малай,
Мин шундый батыр малай!

Үз-үземә сокланып,
Утыра идем хушланып,
Урамда кычкырдылар,
Ярдәмгә чакырдылар.

Чәчемне тараганчы,
Өстемне караганчы,
Көзгегә күз салганчы,
Кулга мылтык алганчы,
Мин лифтны көткәнче,
Баскычлардан төшкәнче —
Тавыш та юк, кеше дә,
Их, күрми калды берсе дә!

Курыкканга — куш

Утны сүндерү белән,
Әллә нәрсәләр күрәм!
Күзне йомарга куркып,
Ятам эчемнән укып.
Почмакта миңа карап
Утыра сыман карак.
Ә караватастыннан
Җен-пәри чыгар сыман.
Юрганны бөркәп баштан,
Укынып яңабаштан,
Чытырдап йомдым күзне,
Санадым илле... йөзне...
Саный-саный арылган,
Күзләр сизми йомылган.
Иртән уянып баксам,
Идәнгә аяк бассам,
Почмакта — карак түгел,
Үсә икән зуп-зур гөл.
Караватасты да буш,
Курыкканга — күренә куш!

Юк, башкача курыкмыйм...
Утны яндырып йоклыйм!



Шапшак

Яңгыр да явып узмады,
Каян пычрак тапкан,
Башыннан аякка кадәр
Бер малай лайга баткан.
Иптәшләре бармак төртеп
Хихылдашып көләләр.
Өлкәннәр үтеп китешли:
«Шапшак!» — диеп сүгәләр.
Ә аның исе дә китми,
Уч төбе кадәр җирдә
Рәхәтләнеп пычрана,
Үтми аңа бер сүз дә.
«Шапшак» диеп исем таккач,
Уйланды бераз малай,
Рәхәт булса да уйнавы,
Пычранмады алай.
Шундый егет башың белән
Ямьсез кушамат тагып,
Ничек йөрмәк кирәк инде
Башны юләргә салып?!
Баксаң, уйнап була икән
Ямь-яшел чирәмдә дә.
Бик теләсәң, чиста килеш
Кайтып була өйгә дә.
Ачуланмый әнисе дә,
Битәрләми әти дә,
Дуслары да үз итәләр,
Көлми хәзер беркем дә!

Сыерчыклар килүгә

Ясадым ояның
Иң-иң-иң зурысын.
Кошларга өендә
Уңайлы, киң булсын.

Саламнан түшәдем
Йоп-йомшак урын-җир,
Караттым көньякка,
Кермәсен салкын җил!

Уянсам бер таңда
Сыерчык сайраугa,
Җыелган кошкайлар
Оялар сайларга.

Шатланып кундылар
Мин элгән ботакка.
«Рәхмәт!» дип ишетелде
Җырлары колакка.

2 3-608

Каргалар тулай торагы

Өянкене сырып алган
Кара каргалар.
Ояларны бүлешәләр
Яз саен алар.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Ялгыштым тагын.
Каргаларга җитәр микән
Оялар саны?

Юкка шикләнгәнмен, дуслар,
Каргалар башлы!
Тулай торак итеп корды
Алар агачны.

Аучы ябалак

Төн утырды ябалак,
Бер тычканны сагалап.
Хәйләкәр шул тычкан да,
Оясына качкан да
Утыра бирә посып,
Бодай бөртеген сосып.
Тамак тук, җылы өе,
Монда аның үз көе.
Йомшак түшәге түрдә,
Таба алмас беркем дә.
Исе китмәде һич тә,
Чыкмады ул бу кичтә.
Күзе талып бетсә дә,
Күпме генә көтсә дә,
Ябалак оталмады —
Тычканны тоталмады.

Ай белән кояш очрашкач

Менә сиңа тамаша,
Күрсәң күзләр камаша —
Ай белән кояш күктә
Очрашканнар лабаса!

Бу нәрсә була инде,
Көнме соң, әллә төнме?
Саташып алар шулай
Йөзәрләр икән күпме?

Мин борчылганны сизеп,
Карады кояш көлеп,
Аңлады бугай ай да,
Юк булды шундук эреп.

Тынычлап калдым мин дә —
Тәртип кирәк һәр җирдә!

Шаян көчек

Бик шаян бер көчек алдык,
Һич тә тик тора белми,
Кайда нәрсә күрә, таба,
Барысын да өйгә сөйри.

Бармак янап, ярамый, дип
Ачулангач бик каты,
Туктады яман шөгыльдән,
Барыбыз да шаккаттык.

Ә бит кайбер шук малайлар
Ачулананны белми,
Угрылыкны кәсеп итеп,
Хәтта масаеп йөри.

Зур үскәч холкың үзгәртү
Авыр булыр аннары.
Маһмай кадәр дә башлары
Юк микәнни аларның?!

Санарга өйрәнәбез

Саный белмәсәң, әйдә,
Өйрәтәмен бер җәйдә!
Бөклә бармакларыңны,
Тырпайт колакларыңны!
Йә, нәрсәдән башлыйбыз?
Берне алып ташлыйбыз.
Ун тавыкка бер әтәч,
Кара, ул нинди ярпач!
Сыерда ике мөгез,
«Миндә дә!» — диде үгез.
Шундый итеп карады,
Котларыбыз калмады,
Дүрт аяклап йөгердек
Нәкъ безнең кәҗә кебек.
Килеп чыктык болынга,
Кемнәр генә юк монда!
Санап бармагың җитмәс,
Көн санасаң да бетмәс.
Бәбкәләр, бәрән, колын —
Чыкканнар тумас борын,
Яшел үлән утлыйлар,
Витаминнар туплыйлар.
Һәрберсен саный торгач,
Ялгышып арый торгач,
Сабырлыгыбыз бетте,
Җитте, дип кайтып киттек.
Тик уйламагыз берүк,
Түземсез болар, диеп.
Иртә белән үк торып
Санарбыз тагын килеп.

Саташкан табигать

Әллә кайчан тау битләре
Кардан ачылган иде,
Елгалар да ярдан чыгып,
Ташу ташыган иде.

Кошлар, җылы яктан кайтып,
Оялар корган иде,
Көннәр дә кояшлы, матур,
Бик җылы торган иде.

Кайдан купты бу ак буран?
Кыш кабаттан килгәнме?
Китмәс борын ук балалар
Сагынган дип белгәнме?

Юк инде, кыш, син ялгышма,
Язга бир тулы ирек!
Күңелләрне без бит язга
Ачтык инде киереп.

Йокы чүлмәге

Киерелә, сузыла,
Күзләрен уа-уа,
Йокыдан тормак була,
Һәм тагын... коймак була.

Эндәшәләр йөз кабат,
Тик җибәрми карават.
Бигрәк йомшак, җылы шул,
Күтәрелми аяк-кул!

Җитмәсә көйсезләнә,
Телләре ямьсезләнә:
«Кычкырып сөйләшмәгез,
Тор инде, дип дәшмәгез,
Кояшны сүндерегез,
Һәм калмасын берегез!»

Кирелеген күр әле,
Әй син, йокы чүлмәге!

Ялкау песи

Аяк арасына сырпаланып,
Мыраулап йөри песи.
Хәйләкәр түгел диген син,
Сизгән ул бәлеш исен!

Әзерне генә ашасаң,
Кем тотар тычканнарны?
«Ялкау», — диеп, үзләре үк
Көләрләр бит аннары!

Өчпочмакмы, берпочмакмы?

Пешергән бүген әнисе
Бик тәмле өчпочмаклар,
Табын янында тып-тыныч,
Селкенә тик колаклар!

Ләйлә генә аптырашта,
Менә сиңа табышмак:
Бер ягын китеп капкан да
Ашадым, ди, берпочмак.

Өлкәннәр аның сүзеннән
Рәхәтләнеп көлделәр.
«Күпме ашасаң да, барыбер
Өчпочмак ул», — диделәр.

Кем хаклы?

Тәгәрәде китте туп,
Һич тотам димә куып.
Тәгәрәп шулай җайга,
Барды да керде лайга.
Аптырап торды Марат,
Пычрак тупка карап.
Бик уйныйсы килсә дә,
Кулын тыгып кесәгә,
Берни булмаган кебек,
Өенә китте кереп.

Бер читтә торган Сәйран
Куркып тормады лайдан.
Алды да тупны юып,
Китте чирәмнән куып.
Әйтерсең торган карап,
Атылып чыкты Марат!
«Минеке ул, бир!» — диеп,
Тупка ябышты килеп.

Калса да шактый хәйран,
Һич шаккатмады Сәйран:
«Мә тубыңны, ал», — диеп,
Җибәрде берне тибеп.
Тәгәрәде китте туп,
Һич тотам димә куып.
Тәгәри торгач җайга,
Барды да керде лайга.
Уйлап кара шулай да:
Хаклык кайсы малайда?

Уенга бирелсәң

Әдилә белән Ләйлә
Дуслаштылар бу җәйдә.
И уйныйлар, уйныйлар,
Уйнап һич тә туймыйлар.

Йокыдан тору белән
Урамда алар гелән.
Өйдә өелгән савыт,
Юарга юктыр вакыт.

Бакчаларны чүп баскан,
Эшләр хәттин күп ашкан.
Өлгергән чакта җимеш,
Кызлар эшкә бик җитез!

Куллары кулга йокмый,
Авызлары буш тормый.
Кылангач шулай һаман
Ачуланган бик яман,
Түзмәгән, ди, кычыткан,
Сабакларын укыткан.



Тау шуганда

Их, рәхәт элдереп төшү
Биек тауның башыннан!
Хәтта җил-җитез җилләр дә
Җитә алмый артыңнан.

Узышуы җилләр белән
Рәхәтен рәхәт тә бик,
Чана тартып менәргә тик
Тавы гына бик биек!



Йорт төзүче

Машинасын көч-хәл белән
Урыныннан кузгатып,
Ихатада эш башлады
Хәйдәр, тузан уйнатып.

Бер ун йөк комын кайтарды,
Күпме суын ташыды.
Йорт салырга кирәк булды
Агачы да, ташы да.

Бик бирелеп китеп эшкә,
Бар дөньясын онытты.
Күрми калды көнбатыштан
Килеп чыккан болытны.

Шыбыр-шыбыр ишә генә,
Кылана яңгыр хәтәр.
Күз ачып йомганчы өйсез
Калды бит безнең Хәйдәр.

Чикерткә

Аралыкта төнозын
Чикерткә сайрап чыкты.
Тәмләп кенә яткан идем,
Күздән качты бар йокы.
Башны мендәр белән каплыйм,
Әйләнәм дә тулганам.
Аптырагач, йә төчкергән,
Йә йөткергән кыланам.
Ә аның исе дә китми,
Ишетмәде дә бугай,
Тартып-сузып таң аттырдым
Җәфаланып мин шулай.
Табын янына җыелгач,
Зарлана гына идем:
«Чикерткәдән ким түгел», — дип
Бабай сүземне бүлде.
Шып булдым!

Муенчак кемгә тиеш?

Акбайны үрти Хәмит,
Күрсәтмәк булып кәмит.
Ниләр генә кыланмый,
Ниләр генә кулланмый!

Касыгына да төртә,
Койрыктан сөйрәп йөртә.
Алҗыды маһмай тәмам,
Үртәлмәс булды һаман.

Колагын тартыйм диеп
Үрелгән иде Хәмит,
Тешләп алды уң кулын —
Малай шундук юк булды.

Ә Акбайны олылар
Муенчаклап куйдылар.
Кинәнә тагын Хәмит,
Күрсәтмәк булып кәмит.

Читтән күзәтеп улын,
Әтисе әйтте шулчак:
«Акбайга түгел, сиңа
Кирәк булган муенчак!»



Катычлы уйнаганда

Качтым шундый шәп җиргә,
Эзләп табармын димә!
Әни эзли бер яктан,
Әби — икенче яктан.
Әти белән бабакай
Караштыра почмактан.

Эзләгән җир калмады,
Тик берсе табалмады!
Кычкырып карадылар,
Елаштырып алдылар,
Йөгереп йөри торгач,
Тәмам хәлдән тайдылар.

Бик кызгандым үзләрен,
Ачтым түзми күзләрем.

Ялкау балыкчы

«Балыкка барасыңмы?» — дип,
Таң белән дустым керде.
Күзләрем дә ачылмаган,
Кая барасың инде!
Шулкадәр җылы юрганны
Ничек ташламак кирәк!
Яр буйлап чыклы үләнне
Ерып атламак кирәк!
Черкиләре мыжлагандыр,
Су буенда салкындыр.
Көндез кояшы кыздырыр,
Йә явып үтәр яңгыр.

«Кәеф юк, — дип киерелдем, —
Бүгенгә бармам инде».
«Тумас борын картайган!» — дип,
Дустым шаркылдап көлде.
Кай арада тотып кайткан
Эп-эре кызылкүзләр!
Кыздырган балык тәмледер,
Ялкауландым ник, җүләр?!

Юри-марый

Кичә елга буенда
Зур бер крокодил күрдем.
Арт чабудан капканчы дип,
Бар көчемә йөгердем.
Гомердә булмаганны
Машинаны узганмын.
Хурлангандыр инде, мескен,
Шоферын бик кызгандым.
Йөгергән чакта хутка,
Тотындым да болытка,
Очтым киттем кош кебек,
Канаттай кулым җилкеп.
Кавказ тавына кундым,
Туйганчы бозда шудым!
Җилдереп төшеп таудан,
Диңгезгә кереп чумдым.
Дельфиннар белән йөздем,
Уйнап шаярдым, көлдем.
Билгесез утрауда
Бераз адашып йөрдем.
Бозау кадәр бер бөркет
Алды да томшыгына,
Кайтарып куйды менә
Мине туган ягыма.
«Чынмы?!» — диеп, малайлар
Миннән ышанып сорый.
Юк ла инде, әкият!
Сөйләдем юри-марый.

Рәхмәт каян төшә?

«Рәхмәт төшкере!» — ди әби,
Ул каян төшә икән?
Төшкән чакта ялгыш тиеп,
Башымны тишмәс микән?

Кәнфит булып төшмәс микән,
Туңдырма булып тагын?
Һичьюгы, бер пепси-кола,
Юкса тәмам сусадым.

Эчтән хыялланып шулай,
Мин әбигә булышам.
Рәхмәт төшсен үземә дип,
Җән-фәрманга тырышам.

Урлашу — начар гадәт

Кәнфит белән чәй эчәргә
Утырган идек тәмләп,
Буп-буш калган кәнфит кабы,
Чак китмәдек тәгәрәп!

Бабай шулчак телгә килде,
Мин кызарганны күреп:
«Тычкан кергән, ахры», — диде,
Мыек астыннан көлеп.

«Урлашсаң — кулың корый», — дип,
Куркыткан була әби.
Шулкадәр котны алырга
Ярамый инде, әйеме?

Сизсә дә: «Син түгелме?» — дип,
Берсе дә бәйләнмәде.
«Мин», — дияргә шул чагында
Һич телем әйләнмәде.

Исән-имин калсам бүген,
Яңадан шул кәнфитне
Авызга да алмыйм, диеп,
Үз-үземә ант иттем.

Кояшка ялвару

Асылынган-бүселенгән,
Көннең чырае сытык.
Болытлар яшь коялар,
Урамда юк һич кызык.

Кичә юкса юри генә
Кояшны сүккән идем,
Кызуга түгел, йөгереп
Мин тирләп пешкән идем.

Ишеткән дә үпкәләгән,
Ахыры, кояш миңа.
Бер елмаеп кара инде,
Башка сүз әйтмәм сиңа!

Әйтүе җиңел

Елама, дип орышалар,
Бигрәк елак син, диләр.
Алар шулай дигән саен,
Минем елыйсым килә.

Әйтерсең лә үзләре гел
Еламыйча үскәннәр.
Әле әнә хәзер дә бит
Елаштыра өлкәннәр.

«Елагач җиңел була», — дип,
Бер-берсен юаталар.
Ә мин елый башладисәм,
Бу хакта оныталар.

Тик торсам

— Аз булса да бер урында
Утырып тор, — ди әни.
Тыз-быз чабулап йөргәнгә
Үзенчә мине әрли.
Аның сүзен тыңлап кына
Тынып торам бер мәлгә.
Йомыла да китә күзләр
Баш тигәнче мендәргә.
Утыруга кәнәфигә,
Тәннәрем хәлсезләнә.
Өстәлдәге балга кадәр
Нигәдер тәмсезләнә.
Оп-олы башы белән, дим,
Ничек шуны аңламый? —
Көнозын йөгереп түгел,
Мин бит тик торсам арыйм

Качышлы

Кайда посып торалардыр,
Һич эзләп табам димә.
Без-без килеп ут сүндергәч,
Черкиләр оча өйдә.

Сизмисең дә, ничек итеп
Борынны тешләп ала.
Иртәнгә — үзләре кача,
Тәндә эзләре кала.

Беркөн мин дә хәйләләдем,
Гел аптырап тормадым,
Яту белән баштанаяк
Юрганыма чорналдым.

Без-без килеп и эзлиләр,
И табалмыйлар мине!
Ничек интеккәннәремне
Алар да белсен дидем.

Әнә шулай кызык иттек,
Һич аптырап тормадык,
Черкиләр белән җәй буе
Без качышлы уйнадык.



Шаярганда

Шаярып кына югыйсә
Башлаган идек сүзне,
Этешеп-төртешеп китеп,
Ватканбыз бит көзгене.

Кичен эштән кайткач әти,
Бастырды да каршына:
— Кайсыгызның эше? — диеп,
Төпченә, сораштыра.

— Мин түгел, мин түгел, — диеп,
Һәркем үзен аклады.
Әти, күпме тырышса да,
Гаеплене тапмады.

Бераз ачуланып алгач,
Безне хәтта мактады:
— Партизан, — ди, — минем кызлар,
Берсен берсе сатмады!

Ярый әле

Ерак-ерак бер йолдыздан
Мин сәлам хаты алдым.
Андагы сәер хәлләргә,
Укыгач, хәйран калдым.

Агачлар да, чәчәкләр дә
Үсми икән аларда,
Иртәләрен чүт-чүт килеп
Кошлар да юк сайрарга.

Кар да яумый, яңгыр да, ди,
Дөньясын ком каплаган.
Ярдәм көтә алар җирдән —
Башка чара калмаган.

Күз алдына китердем дә
Үзебезнең Җир шарын,
«Шундый хәлгә калсак әгәр,
Нишләрсең?» — дип уйладым.
...Бигрәк куркыныч төш күрдем,
Ярый әле уяндым!

Елак малай

Урам уртасында Вәли
Кәҗәләнеп акыра.
Әнкәсе көен табалмый,
Бетте тәмам аптырап.

Кәнфит бирсәң дә туктамы
Бу ниткән кире малай?
Шулкадәр киреләнергә
Ярамый инде алай!

Башыннан да сыйпап кары
Кулга күтәрмәк була.
Аның саен ныграк үкси,
Бигрәк елак бала!

Бар урамны яңгыратты,
Чыдасаң чыда гына,
Үзе кечкенә булса да,
Тавышы бик зур чыга!

Кырау

Кичә генә бакчабыз
Шау чәчәк иле иде,
Иртән уянып баксам,
Каралган барча гөле.

— Кырау суккан, — ди әни, —
Хараплар булган инде!
Тәртипсез ул кырауга
Яман ачуым килде!

Җәйне ямьләп утырган
Гөлләрем бик кызганыч.
Кырауның гүзәллекне
Аңламавы аяныч.

Эзләсәм дә табалмадым
Шул кырауның таягын,
Тапкан булсам, үзенең
Суга идем аягын.

Эчтәлек

Яшенле яңгыр . . . .
Батыр малай . . . .
Курыкканга — куш . . . .
Шапшак . . . .
Сыерчыклар килүгә . . . .
Каргалар тулай торагы 1
Аучы ябалак 1
Ай белән кояш очрашкач 1
Шаян көчек 1
Санарга өйрәнәбез 1
Саташкан табигать 1
Йокы чүлмәге 19
Ялкау песи 19
Өчпочмакмы, берпочмакмы? 21
Кем хаклы? 22
Уенга бирелсәң 23
Тау шуганда 25
Йорт төзүче 27
Чикерткә 28
Муенчак кемгә тиеш? 29
Качышлы уйнаганда 31
Ялкау балыкчы 33
Юри-марый 35
Рәхмәт каян төшә? 36
Урлашу — начар гадәт 37
Кояшка ялвару 38
Әйтүе җиңел 39
Тик торсам 40
Качышлы 41
Шаярганда 43
Ярый әле 45
Елак малай 46
Кырау 47

Литературно-художественное издание для детей младшего школьного возраста

Шарипова Резеда Сарваровна

Ленивый рыбак

Стихи

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Шәрипова Резеда Сәрвәр кызы

Ялкау балыкчы

Шигырьләр

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов.* Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева.* Корректоры *Р.Н.Шакирова.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.07.2006. Форматы 60×90 $^{1}/_{8}$. Кәгазе гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,0. Шартлы буяу-оттиск 25,0. Нәшер-хисап табагы 5,24. Тиражы 5000 д. Заказ З-608. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://www.tatarstan.ru/books/. **E-mail: tki@books.kazan.ru.** Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.